БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2021 ел № 285

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында сугыш вакытында эвакуация чараларын оештыру турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 ДСП номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне мөмкин булган куркыныч зоналардан эвакуацияләүне планлаштыручы, муниципаль берәмлекләргә беркетелгән Татарстан Республикасының имин районнары исемлеген раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 016-596 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә халыкны урнаштыру урыннарында эвакуацияләнә торган халыкны кабул итүне, урнаштыруны, беренче чиратта яшәүне тәэмин итүне планлаштыру буенча идарә органнары эшен оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыру өчен билгеләнгән торак пунктлары исемлеген (1 нче кушымта);

1.2. Районның кабул итү эвакуация комиссиясе турында нигезләмәне һәм аның составын (2 нче, 3 нче кушымталар);

1.3. Кабул итү эвакуация комиссиясе хезмәткәрләренең функциональ бурычлары (4 нче кушымта)

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә (алга таба – Балтач муниципаль районы) эвакуацияләнә торган халыкны кабул итүне, урнаштыруны, беренче чиратта яшәүне тәэмин итүне планлаштыру буенча идарә органнары эшен оештыру максатларында түбәндәге эвакуация органнарын төзергә:

кабул итү эвакуация пунктлары (алга таба - КЭП) (5 нче кушымта);

эвакуацияләнә торган халыкны төшерү пункты (алга таба-ТП) (6 нчы кушымта);

2.1. Кабул итү эвакуация пункты турында нигезләмә (7 нче кушымта).

2.2. Эвакуацияләнә торган халыкны төшерү пункты турында нигезләмә (8 нче кушымта).

2.3. Татарстан Республикасының имин районнары территорияләрендә таралучы һәм эвакуацияләнә торган халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне кабул итүне, урнаштыруны һәм беренче чиратта яшәүне тәэмин итүне оештыру турында нигезләмә (9 нчы кушымта).

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән, төзелә торган эвакуация органнары начальниклары итеп, алар базасында эвакуация органнары төзелә торган оешма һәм учреждение җитәкчеләрен билгеләргә.

4. Карар рәсми басылып чыкканнан соң бер ай эчендә эвакуация органнары (КЭП, ТП) начальникларына формалаштырыла торган эвакуация органнарының шәхси составын билгеләргә, оештыру-планлаштыру документларын эшләргә һәм аларны урнаштыру өчен урыннар билгеләргә.

5. Эвакуацияләнүче халыкны кабул итүне һәм алар карамагындагы территориядә урнаштырны гамәлгә ашыручы Балтач муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә төзелә торган эвакуация органнары (КЭП, ТП) администрацияләренә эшне оештыруда һәм аларны җиһазлауда ярдәм күрсәтүне һәм һәрьяклап ярдәм итүне тәкъдим итәргә.

6. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына кирәкле мөлкәт белән тәэмин итү һәм ана белән бала бүлмәсе эшен оештыру өчен КЭПка янында урнашкан мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен беркетергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов